ГЛАВА САХАРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ САХАРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛАГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.07.2024 с.Сахаровка № 9

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының "Сахаровка авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31-33 статьялары, « Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлегендә гавами тыңлаулар уздыру юлы белән авыл җирлегендә яшәүчеләрнең проект буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында иҗтимагый фикер алышуларны яисә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә белән

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Сахаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш алып Кагыйдәләре проекты (алга таба - Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре проекты) буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә

2. Билгеләргә:

2.1. гавами тыңлаулар үткәрүне оештыручы итеп - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе (алга таба-Комиссия);

2.2. гавами тыңлауларны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны - 2024 елның 16 августы, 10.00 сәгатьтә Сахаровка авыл мәдәният йортының тамаша залында, түбәндәге адрес буенча: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Сахаровка авылы, Мирная урамы, 101 йорт;

2.3. җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре проекты буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, авторның фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын, яшәү урыны адресын күрсәтеп, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Сахаровка авыл җирлеге башкарма комитеты

бинасы, түбәндәге адрес буенча тапшырыла ала: ТР, Алексеевск районы,Сахаровка авылы,Мирная урамы, 100 йорт ( Дүшәмбе – җомга сәгать 8-00 дән 12-00 сәгатьтә һәм 13-00 сәгатьтән 16-00 сәгатькә кадәр, төшке аш тәнәфесе 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр);

2.4. гавами тыңлауларда катнашучыларның җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре пректына тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү срогы- 18.07.2024 елдан 11.08.2024 елга кадәр

3. Сахаровка авыл җирлегендә яшәүчеләр җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре проекты белән алдан ук Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә таныша алалар http://alekseevskiy.tatarstan.ru/ «Градостроительство»,«Проекты Правил землепользования и застройки» бүлегендә.

4. Комиссиягә:

4.1. Гавами тыңлаулар уздыру турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлеге мәгълүмат стендларында һәм Интернет челтәрендә Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга. http://alekseevskiy.tatarstan.ru/.

4.2. билгеләнгән тәртип нигезендә һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре проекты буенча гавами тынлаулар әзерләргә һәм уздырырга;

4.3. гавами тыңлаулар уздыру йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советына гавами тыңлаулар беркетмәсен, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә тапшырырга.

4.4. җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару Кагыйдәләре проекты буенча гавами тынлаулар нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районынын Сахаровка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга (http://alekseevskiy.tatarstan.ru/).

5. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка житкерергә) (http://alekseevskiy.tatarstan.ru/).

**Сахаровка авыл җирлеге**
**Советы утырышында рәислек итүче**
**1 нче сайлау округы депутаты** **Н.И. Леденцов**

Республика Татарстан муниципальное образование "Сахаровское сельское поселение" Алексеевского муниципального района
р05-11124/13
Совет Сахаровского сельского поселения